**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№М 331**
**21.09.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең хокук бозуларны
профилактикалау буенча ведомствоара
комиссиясе нигезләмәсенә
үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2011 елның 11 мартындагы 150 номерлы карары (шәһәр Хакименең 2020 елның 21 июлендәге М 255 номерлы карары редакциясендә) белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында» Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе нигезләмәсенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, кушымтада каралганча үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре
Хакименең 2020 елның
21 сентябрендәге М 331
номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба - комиссия) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затларының, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда, хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруда катнашучыларның килешенгән эш гамәлләрен тәэмин итү өчен төзелгән даими эшләүче муниципаль координацияләү органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, башка муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге нигезләмәгә туры китереп башкара.

2 бүлек. Комиссиянең төп бурычлары

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) җирле үзидарә органнарының һәм хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең законнарын үтәү буенча эшчәнлеген координацияләү, шулай ук Яр Чаллы шәһәре халкы арасында алкогольле продукцияне, сыраны, тәмәкене чиктән тыш күп куллануны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләрен дә кертеп, хокук бозуны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек;

2) комиссия карарлары үтәлешен тәэмин итү;

3) Башкарма комитет Җитәкчесенә Яр Чаллы шәһәре территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге муниципаль программаны тормышка ашыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

4) алкоголизм, наркомания, законсыз миграциягә каршы көрәшне активлаштыруга юнәлтелгән хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар ителгән затларны ресоциализацияләүгә һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә хокук бозулар дәрәҗәсен киметүгә юнәлтелгән башка чараларны эшләү;

5) хокук бозуларны профилактикалауның төп юнәлешләре буенча комплекслы чаралар эшләү, аларны Яр Чаллы шәһәре территориясендә хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашырганда хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затларының, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның гамәли эшчәнлегенә кертү;

6) Яр Чаллы шәһәре территориясендә шәһәр профилактика чараларын, шулай ук Яр Чаллы шәһәре территориясендә хокук бозулар дәрәҗәсен киметүгә юнәлтелгән профилактика чараларын оештыру һәм үткәрү;

7) Яр Чаллы шәһәре территориясендә законсыз корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч матдәләр әйләнешен кисәтү буенча эшне оештыру;

8) хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затлар тарафыннан башкарыла торган эш турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## 3 бүлек. Комиссиянең төп функцияләре

4. Комиссия аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә шәһәр муниципаль программаларын эшләүдә катнаша, шулай ук аларны тормышка ашыруны, шул исәптән әлеге программаларда каралган хокук бозуларны профилактикалау чараларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинг юлы белән контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнаша;

2) хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затларының, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның эше турында мәгълүмати-аналитик, белешмә материаллар, мәгълүматлар әзерләүне һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә мониторинг ясауны гамәлгә ашыра;

3) Яр Чаллы шәһәре территориясендә хокук бозуларны профилактикалау чараларын тормышка ашырганда хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм аларның вазыйфаи затларының, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм тарата;

4) хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл иткәндә иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

5) аның функцияләренә кергән мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

6) хокук бозу күренешләренең торышы һәм тенденцияләре, аның функцияләренә кергән мәсьәләләр буенча превентив эшнең нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат җыя һәм анализлый;

7) комиссия карарлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

## 4 бүлек. Комиссиянең төп хокуклары

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

2) билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрдән һәм башка оешмалардан аның функцияләренә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга;

3) үз утырышларына дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларны чакырырга;

4) хокук бозуларны профилактикалау буенча күрелә торган чараларны, шулай ук хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшчәнлекне координацияләү һәм мониторинглау нигезләрен өйрәнү максатларында кызыксынучы органнар һәм учреждениеләр вәкилләре һәм белгечләре арасыннан эшче төркемнәр төзергә;

5) билгеләнгән тәртиптә хокук бозуларны профилактикалау чараларын тормышка ашыруда практик ярдәм күрсәтү, бу эшне алга таба камилләштерү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр эшләү өчен башкарма хакимият органнары вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларны җәлеп итәргә.

5 бүлек. Комиссияне формалаштыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе

6. Комиссия турында нигезләмә һәм аның персональ составы шәһәр Хакиме карары белән раслана.

7. Комиссия рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

8. Комиссия составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре керергә мөмкин. Кирәк булганда, комиссия составына башка затлар да кертелергә мөмкин. Комиссия әгъзасы вәкаләтләрен башка затка бирү рөхсәт ителми.

Утырышларда комиссия карары буенча аларның компетенциясенә караган мәсьәләләрне тикшергәндә министрлыклар һәм ведомстволар, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре катнаша ала. Кирәк булганда, комиссия утырышларында катнашуга башка кызыксынган затлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре җәлеп ителә ала. Комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычында гамәлгә ашырыла.

9. Комиссия утырышының дәвамлылыгы чикләнмәгән.

10. Комиссия эшчәнлеген оештыру комиссиянең эш планы нигезендә башкарыла. План агымдагы елга комиссия әгъзаларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә төзелә, комиссия утырышында карала һәм аның рәисе тарафыннан раслана. Комиссиянең эш планы расланганнан соң ун эш көне эчендә комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга җибәрелә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.

11. Комиссия утырышлары аның рәисе җитәкчелегендә яисә аның кушуы буенча комиссия рәисе урынбасары җитәкчелегендә үткәрелә һәм аларда аның

составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

12. Комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, кварталга бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булган очракта, комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, шулай ук комиссия әгъзасы инициативасы буенча, комиссия рәисе белән килештереп һәм комиссия секретаре тәкъдиме буенча комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

13. Комиссия рәисе:

1) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге нигезләмә нигезендә комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә һәм аны оештыра;

2) комиссиянең эш планын раслый;

3) комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

4) үз вәкаләтләре кысаларында комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

5) Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча комиссия исеменнән эш итә.

14. Комиссия секретаре:

1) комиссиянең эш планы проектын әзерләүне тәэмин итә, аның утырышының көн тәртибен формалаштыра, комиссия утырышына кирәкле материалларны, тиешле карар проектларын әзерләү эшен координацияли;

2) комиссия әгъзаларына, утырышка чакырылган затларга, экспертларга, башка затларга комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

3) комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

4) комиссия рәисенең комиссия утырышлары нәтиҗәләре буенча биргән йөкләмәләрен үтәүне оештыра.

## 6 бүлек. Комиссия карарын кабул итү тәртибе

15. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән комиссия әгъзаларының язма рәвештә бирелгән фикерләрен исәпкә алып кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Кабул ителгән карар белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язмача бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри беркетелергә тиеш. Аерым фикер комиссия секретарена комиссия әгъзалары тарафыннан комиссия утырышы тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә тапшырылырга тиеш.

16. Комиссия карары комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана. Комиссия утырышлары беркетмәләре утырыш тәмамланган көннән башлап биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

17. Комиссия тарафыннан аның функцияләре нигезендә кабул ителә торган карарлар Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

18. Комиссия карарларын тормышка ашыру өчен шәһәр Хакиме, Башкарма комитет карарлары чыгарылырга мөмкин.

19. Кирәк булган очракта, комиссия секретаре аерым мәсьәләләр буенча комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтәләр әзерли һәм раслый.

20. Беркетмә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында комиссия утырышында рәислек итүче имзалаган көннән башлап ун эш көне эчендә урнаштырыла.

Комиссия рәисе йөкләмәсе буенча комиссия карарлары турында мәгълүмат, бастырып чыгару өчен, массакүләм мәгълүмат чараларына бирелергә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте территориаль органнарының рәсми сайтларында урнаштырылырга мөмкин.

## 7 бүлек. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү

21. Комиссия эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

22. Комиссиянең үз исеме язылган бланкы бар.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева